| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ГЛАВА АХМЕТОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ӘХМӘТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Әхмәт ав. **КАРАР**

17 октябрь 2025 ел № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Әхмәт авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законның 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 12 ноябрендә 09 сәгать 00 минутка Әхмәт авылы, Үзәк урам, 48нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Үзәк урам 2-46нчы йортларда яшәүче гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 12 ноябрендә 09 сәгать 30 минутка Әхмәт авылы, Үзәк урам, 48нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Үзәк урам 1-59нчы йортларда, Үзәк тыкрыгы, Яшьләр урамында яшәүче гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«2026 елда Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан тыш һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге башлыгы Г.Н. Лизратова